ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 26.09.2024 1476 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын һәм күрсәткечләрен раслау турында» 2023 елның 9 ноябрендәге 1766 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 272-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең һөнәри эшчәнлек нәтиҗәлелегенә объектив тышкы бәя бирү һәм матди кызыксындыру нигезендә аларны гамәлгә ашыру максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын һәм күрсәткечләрен раслау турында» 2023 елның 9 ноябрендәге 1766 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын һәм күрсәткечләрен раслау турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары һәм күрсәткечләре» турындагы Нигезләмәнең 1 нче кушымтасындагы 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Региональ, республика һәм федераль дәрәҗәдәге һөнәри осталык конкурсларында педагогларның (җиңүче/призер/ лауреат/финалист) катнашуы нәтиҗәләре | еллык | В/Ах100<br>педагоглар саны исәбеннән, биредә<br>А - агымдагы уку елының 01 сентябренә гомуми белем бирү оешмасы педагогларының гомуми саны;<br>В - агымдагы уку елы йомгаклары буенча конкурсларда җиңүчеләр һәм/яисә призерлар саны | Чагыштырмача авырлык баллар санына тигез |

1.2. «Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары һәм күрсәткечләре» турындагы Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 9 пункт белән тулыландырырга:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9. | 9 нчы сыйныф укучыларының гомуми саныннан «Алабуга Политех» укырга кергән балалар өлеше, процентларда | еллык | 9 нчы сыйныф укучылары саны исәбеннән:<br>В/А х 100**,** биредә<br>А - агымдагы уку елының 1 сентябренә гомуми белем бирү оешмасының 9 нчы сыйныф укучыларының гомуми саны;<br>В - «Алабуга Политех» укырга кергән балалар саны. | Чагыштырмача авырлык баллар санына тигез |

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева